**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39 422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru

ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.04.2020 № 218

**Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен предметлары булып товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү торган контрактларны банк белән тәэмин итү очракларын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен предметлары булып товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү торган контрактларны банк белән тәэмин итү очракларын расларга (1 нче кушымта).

2. Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Контрактларны банк белән тәэмин итү тәртибен, шулай ук предметлары булып товарлар белән тәэмин итү, эшләр башкару, муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен хезмәтләр күрсәтү торган контрактларны банк белән тәэмин итү очракларын раслау турында»гы 2017 елның 3 мартындагы 90 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И. Хисамовага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Б. Семенычев**

Тәтеш муниципаль районы
башкарма комитетының
2020 елның 28 апрелендәге
218 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен предметлары булып товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү торган контрактларны банк белән тәэмин итү очраклары**

Муниципаль заказчы муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен предметлары булып товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү торган контрактларны банк белән тәэмин итү шартын билгеләргә хокуклы:

а) муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын төзү (реконструкцияләү, шул исәптән реставрацияләү, техник яктан яңадан коралландыру) максатларында, тәэмин итүчегә аванс бирүне күздә тотмый торган муниципаль милек объектларын төзү (реконструкцияләү) максатларында;

б) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93 статьясы нигезендә бердәнбер тәэминатчы (подрядчы, башкаручы) белән, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, контракт шартлары нигезендә, куелган товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу, күрсәтелгән хезмәтләр контракт бәясенең якынча бәясеннән чыгып йә бәянең формуласыннан чыгып, аның максималь әһәмиятен күрсәткән очракта.